МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.04.2022 г.Казань № 295

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 11 маенда 9130 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 3 июлендәге 448 номерлы боерыгы белән расланган Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 3 июлендәге 448 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.06.2017 №416, 15.05.2018 №366, 18.09.2018 №886, 16.04.2019 №276, 27.08.2019 №652, 12.11.2019 №984, 06.07.2020 №488, 08.10.2020 №711, 26.02.2021 №114,

17.12.2021 №940 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 19 апрелендәге 295 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 3 июлендәге 448 номерлы боерыгы белән расланган Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнар каплау өчен түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4-1.6 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 1.7 пункт өстәргә:

«1.7. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Акланган гражданнарга телефон кертүгә киткән чыгымнарны кайтару өчен түләү (алга таба – телефон кертүгә киткән чыгымнарны кайтару өчен түләү) билгеләү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) күрсәтелә.

Үзәккә карата гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

2.2.2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Телефон кертүгә киткән чыгымнарны кайтару өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар.

Кәгазьдә карар әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә форма буенча рәсмиләштерелә. Нәтиҗәне кәгазьдә теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча.

### 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры

2.4.1. Телефон кертү чыгымнарын кайтару өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза теркәлгән көннән алып, биш эш көне эчендә кабул ителә.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчегә телефон кертү чыгымнарын кайтару өчен түләү билгеләү турында кабул ителгән карар хакында гаризада күрсәтелгән ысул белән (язма формада почта адресы буенча, электрон документ формасында электрон почта аша, телефонга смс-хәбәр итеп) хәбәр итү җирләү чыгымнарын кайтару өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.3. Телефон кертү чыгымнарын кайтару өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында хәбәр юлланган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, телефон кертү чыгымнарын кайтару өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

2.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта яки электрон адреска) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

### 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Министрлыкның рәсми сайтында: http://mtsz.tatarstan.ru урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Үзәк бүлекчәсе, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

### 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет белешмәләрен күрсәтеп, әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә телефон кертү чыгымнарын каплау өчен түләү билгеләү турында гариза;

2) затның акланган гражданнар категориясенә керүен раслаучы документ күчермәсе;

3) телефон кертү буенча күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләү турында документ күчермәсе;

4) ышанычнамә күчермәсе, әгәр телефон кертү чыгымнарын кайтару өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырылса;

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә

Документларның күчермәләре нотариус тарафыннан яисә документның оригиналын биргән орган (учреждение) тарафыннан таныкланмаган очракта, алар чын нөсхәләре белән бергә тапшырыла һәм Үзәк бүлекчәсе белгече тарафыннан таныклана.

Гариза почта аша җибәрелгәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклау шәхси кабул итү вакытында Россия Федерациясе гражданины паспортын яисә, Россия Федерациясе законнары нигезендә яки «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы федераль законның $14^1$ статьясының 18 өлешендә каралган мәгълүмат технологияләрен кулланып, идентификация һәм аутентификация ярдәмендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар:

шәхси счетның иминият номеры турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булу (булмау) турында.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда аталган белешмәләрне үз эченә алган әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта

каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

документлар белән әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булуы;

Үзәк бүлекчәсенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру;

күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән мөрәҗәгать иткәндә төп документларның күрсәтелмәве;

мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

гаризаның мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча бирелмәве.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча бурычы булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы.

мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында сорап мөрәҗәгать иткән көннән соң 90 көн эчендә җайга салынмаган булса.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гариза һәм документлар кергән көннән башлап бер көн эчендә

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) аларны тутыру үрнәкләре һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге белән мәгълүмати стендлар урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы

боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидлыгы булган затларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлеген тудыру өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктасы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәтенең сыйфаты һәм һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Үзәк бүлекчәләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итела торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда хезмәттәшлек итү саны – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан алынырга мөмкин.

2.13.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮ ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

Телефон кертү чыгымнарын каплауны билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә дә;

гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) телефон кертү чыгымнарын каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүчегә тапшыру яки дәүләт хезмәте нәтиҗәсен почта буенча җибәрү;

техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон, почта аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша Үзәк бүлекчәсенә дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Үзәк бүлекчәсе белгече шәхсән, телефон аша, почта, электрон почта ярдәмендә, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча, гариза бланкы бирә һәм, зарурлык булганда, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: консультацияләү, тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

Мөрәҗәгать итүче телефон кертү чыгымнарын каплауны билгеләү турындагы гаризаны Үзәк бүлекчәсенә әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә документларны теркәп тапшыра.

Гариза һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның күчермәләре почта юлламасы итеп җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап язу тапшыра, гариза почтадан һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгәндә, – гаризаны теркәү датасы һәм беркетелгән керү номеры турында хәбәр җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Үзәк бүлекчәсе белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм докуметлар Үзәк бүлекчәсенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлекчәсенең эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы эш көнендә. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлекчәсенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, документларны кабул итү турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр төзү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.4.1. Телефон кертү чыгымнарын каплауны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында вәкаләтле органнарга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булу (булмау) турында;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара гаризалар формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматларны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматларның булмавы турында белдерү җибәрә.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек эшендә катнаша торган органнар әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән документларны законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүмат яки мәгълүмат булмау турында

белдерүләр.

3.5. дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) телефон кертү чыгымнарын каплау өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү;

3.5.1. Үзәк бүлекчәсе белгече алынган, әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә, шулай ук мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8.1 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 3 нче һәм 5 нче кушымталары нигезендә телефон кертүгә чыгымнарны каплау билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яисә хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештә карар проектын рәсмиләштерә;

телефон кертүгә киткән чыгымнарны кайтаруны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яисә хезмәт күрсәтүне туктатып тору турындагы электрон рәвештәге карар проектын Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзага җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: телефон кертү чыгымнарын каплауны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында электрон карар проекты.

3.5.2. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе телефон чыгымнарын кайтаруны билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) яисә хезмәт күрсәтүне туктатып тору турындагы электрон рәвештәге карарга электрон цифрлы имза куя һәм Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны телефон кертүгә чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты җибәрелгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе имзалаган телефон кертүгә чыгымнарны каплауны билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында белдерү

Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карарга кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту яки чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү

Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатып торылган вакыт эчендә мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмәләр алынса яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән бурычны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылган очракта, Үзәк бүлекчәсе белгече:

әлеге Регламентка 5 нче кушымта нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карар проектын электрон рәвештә рәсмиләштерә;

әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту һәм чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турындагы карар проектларын Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалу өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча бурыч булуы (булмавы) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бурычларны җайга салуны раслый торган документлар тапшырылганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында карарлар проектлары.

3.5.5. Мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча бурычларны җайга салмаган очракта, чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында гариза биргән көннән соң 90 көн узгач, Үзәкнең бүлек белгече чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли һәм Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында гариза бирелгән көннән соң 90 көн узгач, аннан соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.6. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турында карар проектларын яисә чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турында карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалый һәм Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында һәм чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләү турындагы карар проектларына яисә чыгымнарны каплау өчен түләү билгеләүдән баш тарту турындагы карар проектына кул куелганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү һәм чыгымнарны кайтаруны билгеләү яки чыгымнарны кайтаруны билгеләүдән баш тарту турында карарлар.

Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан чыгымнарны кайтаруны билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында карарга кул куелганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлекчәсе белгече телефон кертү чыгымнарын кайтару өчен түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

